**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2026 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Электр техникасының теоретик нигезләре» кафедрасы доценты Галиева Татьяна Геннадьевнага – электр энергиясе тапшыру линияләре һәм ярдәмче станцияләрнең югары вольтлы изоляторлары техник торышын мониторинглау системасын эшләүгә зур өлеш керткәне өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Инженерлык графикасы» кафедрасы мөдире вазыйфаларын башкаручы Зиннуров Вадим Эдуард улына – күп санлы көчле һава агымнары аппаратларында дисперс тирәлекләрнең бүленүе механик процессларын тикшерүгә зур өлеш керткәне өчен;

3) физика-математика фәннәре кандидаты, «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «КАИ-КВАНТ» Казан квант үзәгенең интеграль квант оптикасы лабораториясе фәнни-укыту лабораториясе фәнни хезмәткәре Миңнегалиев Мансур Марсель улына – ерак арада гамәлдә булган квант коммуникацияләре өчен мәгълүмат саклау оптик квант җайланмасын эшләү һәм тикшерүгә зур өлеш керткәне өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 16 июнь
№ 484